КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 6 сентябрь г.Казань № 826

Дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларның түләүсез кайнар ризык белән туклануын оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәтен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2022 елга дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларның түләүсез кайнар ризык белән туклануын оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны бер көнгә бер белем алучыга – 55,55 сум, 2023 елга – 57,77 сум, 2024 елга – 60,08 сум күләмендә;

2022 елга башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәтен – 55,55 сум, 2023 елга – 57,77 сум, 2024 елга – 60,08 сум күләмендә.

2. Җирле үзидарә органнарына муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларның түләүсез кайнар ризык белән туклануын оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны бер көнгә бер белем алучыга билгеләү буенча шундый ук карарлар кабул итүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру һәм тәэмин итү өчен норматив чыгымнарны раслау турында» 2020 ел, 6 октябрь, 908 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин